СОВЕТ КАТМЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Киров урамы, 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422177

Тел. (факс): (85563) 2-72-03 e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www;mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**

“18” сентябрь 2019 ел №1-47

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советы К А Р А Р К А Б У Л И Т Т Е:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

*- Катмыш авылы Ленин урамында, Еникей Чишмә авылы Совет урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эшләр өчен түләү);*

*- Катмыш, Баскан, Еникей Чишмә авыллары юлларын кардан чистарту;*

*-Катмыш һәм Баскан авылларында чишмә төзекләндерү (материал, җиһазлар сатып алу, килешү буенча түләү);*

*- Катмыш, Баскан, Еникей Чишмә авылы елгалары янында янгын техникасы белән су алу өчен пирс булдыру ( сатып алу, ташу, таш җәю, килешү буенча түләү).*

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru,) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башлыгы И.Г.Габидуллинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе И.Г.Габидуллин

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КАТМЫШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1626001210